# Нәсыйхәт

чәршәмбе
24
октябрь
2012 №18

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы


## Яңалыклар

**ГЫЙЛЕМ ЭСТӘДЕ.** Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт 1нче октябрьдән алып 7нче октябрьга кадәр Казанда үткәрелгән квалификация арттыру курсларында булып кайтты. Дәресләрне Кувейттан килгән профессор Ахмәд Хаҗи Аль-Курди алып барды. Курслар азагында аттестацион имтиханнар үткәрелде. Имтиханнарны яхшы биргән укучыларга шаһәдәтнамәләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**САМАТОВ УКУЛАРЫНДА.** Мәдрәсә мөгаллиме Ранил хәзрәт Казанда һәр елны үткәрелеп килә торган Саматов укуларында катнашты. Ул анда “Ризаэтдин бине Фәхреддиннең “Әдәбе тәгълим” китабында Ислам педагогикасы” дип аталган доклад әзерләде.

**УКУЛАР ГӨРЛИ.** Мәдрәсәдә һәр елдагыча 1нче октябрьдән кичке укулар башланып китте. Быел да укучылар мәдрәсәгә теләп йөриләр. Алар арасында өлкән буын белән берррәттән яшьләр дә бихисап. Монда шулай ук төрле һөнәр ияләрен дә күрергә була: табибләр, укытучылар, тәрбиячеләр... Әмма аларның барысын да дингә мәхәббәт берләштерә. Аллаһ аларга хәерле гыйлем насыйп итсен.

**МӘКТӘПКӘ ЯРДӘМ.** Мәдрәсә мөгаллимнәре коррекцияләү торак-мәктәбендә кунакта булдылар, балаларга үзләренең үгет-нәсыйхәтләрен җиткерделәр. Бирегә алар буш кул белән килмәделәр. Халыктан җыелган киемнәрне тапшырдылар. Балалар әлеге бүләкләргә шат калдылар.

# КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



**–“Корбан” нәрсәне аңлата?**

–Ислам буенча корбан чалу – эре һәм вак мөгезле терлекне Аллаһның ризалыгы өчен бәйрәм көннәрендә чалу. Бу “Кәүсәр” сүрәсендә чагыла: “Раббының ризалыгы өчен намазны үтә һәм корбан чал”.

**–Корбан чалу ислам динендә нинди урын тота? Ул һәркем өчен дә мәҗбүриме?**

–Мөселман кешегә ел саен корбан чалу вәҗиптер. Аллаһның илчесе галәйһиссәлам: «Кемнең корбан чалырга мөмкинлеге булып та, моны эшләмәсә, мәчетебезгә якынлашмасын»,–дип кисәткән. Шулай да хәлләреннән килмәгәннәр өчен мәҗбүри дип саналмый.

**–Корбан чалмыйча, чалдырмыйча акчасын гына мәчеткә яки мескеннәргә бирергә ярыймы?**

–Корбан чалу–кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе. Корбан чалуны акча биреп кылына торган гыйбадәткә әйләндерү дөрес дип әйтеп булмас.

**–Корбанлык өчен нинди хайван сайлау кирәк?**

– Корбанлык өчен пар тояклы — кәҗә, сарык, дөя, сыер кебек хайваннарны алу кирәк. Каз, үрдәк, күркә кебек кошларны, атларны чалырга ярамый. Шулай ук авыру, сукыр, аксак, тешсез, колаксыз, койрыксыз һәм бик ябык яки буаз хайваннарны корбанга чалу дөрес түгел. Яшенә килсәк: дөягә–биш, үгез яки сыерга–ике, кәҗә, сарык малына бер яшь булу шарт. Соңгылары исә бик зур һәм симез булып, бер яшьлекләреннән аерылмаса, алты айлыкларын да чалу ярый. Ә эре маллар бу кагыйдәгә карамый. Тик шунысын истән чыгармаска кирәк. Сарык һәм кәҗә бер кеше өчен генә корбан кылына, ә сыер яки дөя–җидешәр кеше өчен. Шулай ук бер үзеңә бер сыер, бер дөя корбан чалу да дөрес. Андый ук мөмкинчелеге булмаган кешеләргә бөтен гаиләгә бер корбан чалырга да ярый.

**–Нәзер итеп чалына торган корбаннар бар. Монда берәр нинди чикләүләр, халык белеп бетермәгән гамәлләр бармы?**

–Нәзер корбанын нәкъ гает көнендә чалу мәҗбүри түгел. Бу эшне башка көнне башкарсаң да була. Кемгә нәзер итеп әйткәнсең, шуңа атап чаласың. Мондый итне үзеңә ашарга ярамый, тулысынча таратып бетерергә яисә кеше җыеп аш үткәрергә кирәк. Үзеңә бары тик шулпасын гына эчәргә була.

**–Корбанлыкны ничек дөрес итеп бүлергә?**

–Аллаһның илчесе галәйһиссәләм шулай аңлатты: «Ашагыз, ашатыгыз һәм саклагыз». Шуңа да итне өч өлешкә бүлү хәерлерәк. Өчтән берен бәйрәм табыны әзерләргә, өчтән берен туганнарга һәм мохтаҗларга өләшергә, калган өчтән бер өлешен үз гаиләңә калдырырга. Шулай ук аш үткәрмичә, калган өчтән ике өлешен фәкыйрьләргә, туган-тумачаларга, күрше-күләннәргә таратырга да мөмкин. Ә тиресен исә сатып, акчасын сәдака итеп бирергә була.

**(Дәвамы 2нче биттә)**

# КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**(Ахыры. Башы 1нче биттә)**

**–Корбан чалу вакыты кайчан?**

–Корбан чалу гает намазыннан соң үтәлергә тиеш. Әгәр гает намазына кадәр чалынган булса, ул корбан чалу үтәлгән дип саналмый. Корбан чалына торган вакыт: гает намазыннан соң башлап, уникенче Зөлхиҗҗәнең ахшам вакытына кадәр. Бу вакыт эчендә корбан бугазлый алмаган кешегә, әгәр корбанлыгы алынмаган булса, корбанлыкның бәһасен сәдака кылу вәҗип буладыр, әгәр корбанлыгы алынган булса, ул очракта корбанның үзен сәдака кылу тиеш. Корбанны унынчы Зөлхиҗҗәдә бугазламый калса, унберенче, уникенче Зөлхиҗҗәдә бугазлау да дөрес булыр. Әмма уникенче Зөлхиҗҗәдә Кояш батканнан соң бугазлау дөрес булмас. Әмма көннәр хисабында хаталык һәм бәхәсләрдән котылу өчен, корбан чалуны бәйрәмнең өченче көненә калдырмау хәерлерәк санала. Иң яхшысы – корбанны беренче көндә чалу.

**–Кояш баткач, караңгы вакытта корбан чалынамы?**

–Корбан чалу– бәйрәм көннен санап, өч көн дәвам итә. Өченче көннең кояшы баеганчы корбан суюлар тәмамланырга тиешле. Иң яхшысы–бәйрәм көнендә чалып эшен бетерү. Ахшамнан соң корбан чалу–мәкруһ. Бу–элеккеге заманнарда электр булмаганлыктан, төнлә караңгы вакытта чалу хаталык белән кылынмасын өчен әйтелгән.

**–Әгәр кеше кушылган көннәрдә корбан чалып өлгермәсә нишләргә?**

–Матди яктан мөмкинчелекле кеше, теләге булып та, вакытында суя алмый калса, бер куй (сарык) сатып алырдай акчасын сәдака итеп мескеннәргә бирер.

**–Кайбер гаиләләр корбанны гает намазына кадәр чалып куя. Болай эшләү дөресме?**

–Гает укылганчыга кадәр чалынган корбан дөрес булмый. Моның турында пәйгамбәребез дә әйтеп калдырган. «Кем гаеткә кадәр корбан чала, бу аның гаиләсе өчен ит кенә булыр, ә корбан чалу фарызы аның өстеннән төшмәс», – диелә анда.

**–Корбан чалуны кем үтәргә тиеш?**

–Корбан чалуны һәр кеше үзе үтәсә әйбәтрәк. Иң башта терлекне кыйблага каратып яткырырга кирәк. Ул аягында чакта корбан догасы укыла. Аннары «Әй, Раббым! Ошбу хайванны Синең әмерең буенча чаламын. Әй, Раббым! Кабул кыл. Бисмиллаһи, Әллаһү әкбәр!»–дип ниятләп, корбанлык бугазы киселә. Әгәр төрле сәбәпләр аркасында кеше бу эшне үзе башкара алмый икән, башка кешегә тапшырып, карап тора ала. Тик өч шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, бу кеше мөселман булырга тиеш. Икенчедән, корбан чалуны үтәүченең: «Әй Аллаһ, бу (корбан) Синнән, һәм Сиңа (кайта), фәләннән кабул ит»,–дип әйтүе кирәк. Өченчедән, ул кешегә чалына торган корбанның ите белән түләргә ярамый.

**–Корбан чалынган хайванның сөякләрен күмәргә кирәкме?**

–Әгәр сөякләр теләсә кайда ятмасалар, күмү ихтыяҗы юк. Хайванның сөякләре һәм каны ислам буенча изге саналмыйлар.

**–Хайванның нинди физик кимчелекләре яки гариплекләре булганда, аны корбан чалырга рөхсәт ителми?**

–Беренчедән, ачыктан-ачык авыру хайван; икенчедән, дөм сукыр; өченчедән, аксак; дүртенчедән, ашарга яраклы нинди дә булса әгъзасы (мәсәлән, койрыгы) булмаган хайван. Шуңа күрә мөгезләре киселгән яки печтерелгән хайван корбан чалу өчен туры килә.

**–Корбан чалганда хайванны кыйбла тарафына юнәлтү вәҗипме?**

–Галимнәр моны һәрбер изге гамәл вакытында, хәтта йокы һәм ял вакытында да, кыйблага юнәлүнең мөстәхәб булуы белән аңлаталар. Шулай ук корбан чалганда хайванны саклык белән сул ягына яткырырга һәм башын күтәреп кую мөстәхәб санала.

**Мөһим искәрмәләр:**

**Җан биргәнгә кадәр хайванны тунарга ярамый.**

**Дөя яки сыерны корбан чалганда (аны корбан чалуда бердән җидегә кадәр кеше катнаша ала) барлык катнашучыларның нияте корбан чалу булырга тиеш. Әгәр катнашучыларның берсенең максаты корбан чалудан ит кенә алу булса, йолада катнашучыларның барысының да корбан чалуы дөрес түгел дип санала.**

## Республика яңалыклары

### “СӨЛӘЙМАН” МӘЧЕТЕ КОРБАНГА 600 САРЫК ЧАЛАЧАК

“Сөләйман” мәчете Корбан бәйрәменә 600 сарык әзерли. Чалып, эшкәртеп, тураклап бирү белән бергә сарыкның бәясе 6800 сумга төшә.




Казанның Левченко поселогындагы “Сөләйман” мәчете Корбан бәйрәменә сентябрь аеннан ук әзерләнә башлады. Сарыкларны тотасы, чаласы урыннар алдан ук әзерләнеп куелды. Корбан көнне мәчеттә өч кешедән торган 20 бригада эшлиячәк. Узган ел “Сөләйман” мәчете 400 баш корбан чалган булган. Быел аларның саны 600 гә җитә. Корбанның бер өлешен ятимнәргә, мохтаҗларга тапшыралар. Инде белгәнебезчә, “Сөләйман” сукырларны укыту белән шөгыльләнә. Итнең бер өлешен сукырларга калдыру мәчеткә зур ярдәм булачак.

### БАШЛАНГЫЧ ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ МӨГАЛЛИМ ҺӘМ МӨГАЛЛИМӘЛӘР КАЗАНГА ҖЫЕЛДЫ

5нче октябрьдә Россия Ислам университетында мәчет каршындагы дини курслар мөгаллимнәренең республика күләмендәге киңәшмәсе уздырылды. Икенче тапкыр үткәрелгән киңәшмәне Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам университеты белән берлектә оештырды. Чарага һәр мөхтәсибәттән башлангыч дини белем бирүчеләр чакырылган иде. 80нән артык мөгаллим һәм мөгаллимә катнашты.



### КҮЗЛӘРЕ КҮРМӘҮЧЕ МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ТӨЗЕЛҮЧЕ ТЕРНӘКЛӘНДЕРҮ ҮЗӘГЕНДӘ КИҢӘШМӘ БУЛЫП ҮТТЕ

5 нче октябрь көнне Серов урамында Күзләре күрмәүче мөселманнар өчен төзелүче Тернәкләндерү үзәгендә Казан мэры Илсур Рәис улы Метшин катнашында киңәшмә үткәрелде. Анда мәркәзебездәге район хакимиятләре башлыклары, Казандагы «Сөләйман» мәчете имам-хатибы Илдар хәзрәт Баязитов һәм башкалар катнашты.



**Татар-ислам сайтыннан алынды**

# Ризаэддин Фәхреддиннең “Әдәбе тәгълим ” китабында Ислам педагогикасы



**Бүгенге җәмгыятькә фәннәрне яхшы үзләштергән, иҗади фикерләүче һәм үз белемен мөстәкыйль рәвештә өзлексез күтәрә белүче кешеләр кирәк.**

Заман мәдрәсәләр алдына түбәндәге бурычларны куя: катлаулы, һаман үзгәреп торучы шартларда яшәргә, эшләргә, социаль кыйммәтләр системасында үз урынын табарга сәләтле шәхес тәрбияләү. Мәдрәсә, андагы укыту-тәрбия процессын Риза Фәхреддиннең бүгенге ислам мәгарифе өчен дә әһәмиятен югалтмаган педагогик хезмәтләреннән башка күз алдына китерү һич тә дөрес булмас иде. Чөнки галимнең өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә дә аваздаш. Ризаэддин Фәхреддин – мөгаллимлек һөнәренә гомере буе тугрылыклы булып калган шәхес. Ул педагогиканың нечкәлекләрен шулкадәр тирән белеп, искиткеч күп мәгълүматлар туплап, үзенең актуальлеге белән бүген дә тиңе булмаган һәм һәр мөгаллимнең өстәл китабы булырлык бик күп хезмәтләр язган. Мисал итеп, галимнең уку-укыту өлкәсенә кагылышлы “Әдәбе тәгълим” (“Укыту кагыйдәләре”) исемле хезмәтен китерергә мөмкин. Әлеге хезмәт моннан бер гасыр элек язылса да, бүгенге көн өчен дә үзенең зур әһәмиятен югалтмаган. Бу китап күп тапкырлар кабат-кабат зур тиражлар белән басылып таралган һәм һәр мәдрәсә мөгаллименең өстәл китабы булган. Галим бу зур күләмле җитди фәнни хезмәтендә мәдрәсәләрнең эшен яхшырту юнәлешендә зур үзгәрешләр, яңалыклар кертү турында эшлекле тәкъдимнәр күтәрә. Автор дистәләрчә гасырлар дәвамында яшәп килгән һәм көндәлек гамәлдә булган халык педагогикасы алымнарына мөгаллим-тәрбияче буларак үз тәҗрибәсеннән алып өстәп баеткан укыту-тәрбия чараларын кушып, шуның өстенә, төрле буын укучы шәкертләрнең физиологик һәм психологик, шулай ук акыл үзенчәлекләрен дә истә тотып, аларның һәрберсенә шәхсән якын килү юлы белән эш итәргә кирәклеген бик җентекләп өйрәтә.Мөгаллим-тәрбияче кешенең үтә дә авыр, җаваплы һәм бик четерекле эшенең бөтен нечкәлекләрен белеп, аларга һәр очрак өчен бик төпле, кирәкле һөнәри киңәшләр бирә. Китапның беренче бүлеге «Гыйлем. Мөгаллим. Тәрбия» дип исемләнгән. Монда шәкертләрнең иң изге һәм олы вазыйфалары – гыйлем үзләштерү, ә аларны гыйлем белән тәрбияләү – мөгаллимнәрнең бурычы икәнлеге аңлатыла. «Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, шәригатебездә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү – укытучының беренче эше булыр», – ди Риза Фәхреддин. Мөгаллим нинди сыйфатларга ия булырга, дәресләрен ничек укытырга һәм аның вазыйфалары нидән гыйбарәт булырга тиеш – бу китапта барысы да төгәл язылган. Ризаэддин Фәхреддин мөгаллимнәргә карата куела торган унөч вазыйфага туктала. Китапта бирелгән бу вазыйфалар һәрбер мөгаллимгә даими рәвештә үз эстендә эшләргә, балаларга тәрбия бирүдә төп этәргеч булып торалар.

Таләпләрнең иң беренчесе – беренче вазыйфа «Холык һәм гамәл» дип атала. Чыннан да, күркәм холыкка ия булган мөгаллимнең генә үз укучыларында да күркәм холык тәрбияли алуы бәхәссез. Мөгаллим яки тәрбиячене гамәле аның холкы белән тәңгәл килгәндә генә гамәл нәтиҗәле була. Без үзебезнең холык һәм гамәлләребезнең тулы чагылышын укучыларыбызда күрәбез. Һәрбер укучыга олы шәхес итеп караганда гына эшнең нәтиҗәсе дә яхшы була. Бөтен рухында, күңелендә күркәм гамәлләре булган мөгаллимнәр генә шәкертләргә үрнәк-күчергеч булып тора.

Икенче вазыйфа – «Белемнәр һәм булдыклылык». «Мөгаллимнең тиеш булачак белемнәрне белүе, мөгаллимлек итәргә кулыннан килүе, булдыклылыгы тагын да күбрәк тиештер», – дип яза ул. Чыннан да, мөгаллимнең төпле белемнәргә ия булуы, аны дөрес итеп җиткерә белүе, шәкертнең өзлексез фән үрләрен яулавында күренә.

Риза Фәхреддин алдагы вазыйфаларда бер-бер артлы ихласлылык, дикъкатьлелек, тырышлык, теләктәшлек, хөрмәт, дөреслек, игътибар һәм белем алуга кызыксыну тәрбияләүне күрсәтә. Ул шәкертнең һәрьяктан камил шәхес булып җитешүе өчен, бөтен җаваплылыкны мөгаллимгә йөкли һәм болай ди: “Шәкерт ничек кенә яшь булса да, ул мәгърифәт үзләштерергә сәләтле булыр, фәкать мөгаллимнең укыту ысулын белүе һәм алдында утырган көчсез җан иясенең киләчәк көндә мәшһүр һәм файдалы адәм булу ихтималы барлыгын фикерләп, саклык белән тәрбияләве шарттыр”. Шәкертләр гыйлемнең әһәмиятен аңлап, тырышып укыйлар икән, димәк бу үз чиратында мөгаллим эшенең күркәм нәтиҗәсе.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрен, аның «Әдәбе тәгълим» педагогик китабын куллану – киләчәк буынны шәхес итеп тәрбияләүдә отышлы чара. Бу китапны һәр дәрәҗәдәге мөгаллим- тәрбияче, бигрәк тә мөгаллимнәр әзерли торган махсус дини урта һәм югары уку йортлары шәкертләре һәм мөгаллимнәре үз һөнәрләренең устав программасы итеп укып өйрәнсәләр дә бик яхшы булыр иде. Чөнки бу хезмәттә әлеге бик борынгы һәм иң изге һөнәрнең бөтен нечкәлекләре ачык бирелгән һәм ничек эш итәргә кирәклеге бик тәфсилләп өйрәтелгән. Ул һәркемнең өстәл китабы булса иде!

**Мәдрәсә мөгаллиме РАНИЛ ТАЛИПОВ әзерләде.**

## Балалар сәхифәсе

# Аллаһ–бер!



**Морат кычкырып китап укый иде: “Барлык Аллалар да Марска җыелгач, күк Алласы җир Алласына күзе белән ялтыратты. Аның бу ялтыратуы яшенгә тиң, ә тавышы күк күкрәвенең бәрүе кебек иде: “Мин сине юк итәм!” Күк Алласы Су Алласын күзәткәндә аңа көнчелек һәм явызлык белән карады”.**

–Ниндидер буш сүз бу,– диде Морат һәм китапны япты. Әтисенә мөрәҗәгать итте:

–Әти, син ничек уйлыйсың, бу дөресме, юкмы? Гомумән, Аллалар шулай күп була аламы һәм алар бергә тату яши алырлармы?”

–Әлбәттә, улым, бу бары тик буш сүзләр генә. Безнең Раббыбыз бер һәм ул–Аллаһ. Әгәр дөреслектә күп Аллалар булса, алар чыннан да талашырлар иде.

–Ә ни өчен, әти?

–Мәсәлән, әгәр бер Алла кояшның яктыртуын теләсә, ә икенче Алла яңгыр явуын, өченчесе караңгы булуын теләсә, һ.б.

–Боларның бөтенесе дә ни белән бетәр иде?

–Болай булса, галәмдә тәртип булмас иде, ел фасыллары бер-берсе белән чиратлашып бармаслар, кояш та иртә белән тормас, ә ай һәм йолдызлар төннәрен барлыкка килмәсләр иде.

Һәрбер гаиләдә бер башлык бар, һәрбер сыйныфның бер җитәкчесе бар. Шуңа күрә җир шарының да хуҗасы булырга тиеш һәм ул –Аллаһы Раббыбыз.

**Мәдрәсә мөгаллиме ИРЕК хәзрәт НУРИЕВ тәрҗемә итте.**

Укучы хаты

# Укы намаз!



**Иң бәхетле кеше –биш вакыт намазын үтәп, иман белән яшәүче.**

Мин күптән түгел намазга бастым. Элек тә намаз укучыга шулкадәр хөрмәт белән карый идем. Беркөнне мәчеткә кердем. Максатым–үземнең сәламәтлегем өчен дип сәдака биреп, дога кылдыру иде. Чөнки нык авырттым. Шулчакта үзебезнең “Изне Нур” мәчетендә эшләүче Мансур хәзрәт намазга басарга теләвемне аңлагач, миңа шундый киңәшен бирде: “Биш вакыт сиңа башлау белән авыр булыр, иртәнге намаздан тотын!” –диде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын аңа. Аннан Әминә абыстайга барып, аның белән бергәләп, өйлә намазын укыдык. Ул да миңа киңәшләрен бирде. Әминә абыстайга исәнлек-саулык, бәрәкәтле гомер телим. Догаларны да яттан белмим, кәгазьне урындыкка куеп, карап укый идем. Аллаһы Тәгалә риза булсын! Ул үзе ярдәм итә икән, догалар истә кала башлады. Хәзер мәдрәсәгә йөреп, намазларымны дөреслим. Чөнки намаз Аллаһы Тәгаләнең фарызы, боерыгы. Дин юлына баскан кешенең иң зур табышы–күңел тынычлыгы. Моның шулай икәнлегенә мин инандым. Намазга баскач сәламәтлегем яхшырды, тормыштан ямь һәм тәм табып яши башладым.

*Дөрес юлны табыйм*
*дисәң,*
*Намазларга бас бүген.*
*Сихәтләнеп киткәнеңне*
*Аңларсың шуннан үзең!*

Намазның әһәмияген аңлата торган бер риваять тә тәкъдим итим әле. Мин аны “Авырмас өчен 101 киңәш” газетасыннан алдым.

Борын заманда ике күрше яшәгән. Моның берсе Аллаһка, икенчесе малга табына торган булган. Аллаһа табына торганы тыйнак кына йортта яшәгән, артык мал җыймаган, бишвакыт намазын калдырмаган, ураза тоткан. Ә бай күрше... Ул катлы-катлы йорт салдырган, хисапсыз мал җыйган. Малы белән мактанган, горурланган. Беркөнне бай җәйге төнне урамга чыгып, биек йортына карап мактанып торганда, төнге намазын үтәп кайтучы күршесен күрә. Күршесен кимсетеп: “Намаз укый-укый җүләрләнәсең бит инде”, –дип мыскыл итә. Шул көнне ут чыгып байның мал-мөлкәте янып бетә. Гомер буе җыйган малы мизгел эчендә көлгә әйләнә. Хәсрәттә калган байны, күршесе өенә алып керә, гаиләсен туендыра, кияргә кием, ашарга ризык бирә. Байның дуслары килеп хәлен дә белмиләр. Булып узган хәлләрдән соң бай тәүбәгә килеп, күршесеннән гафу үтенә һәм үзе дә ислам динен кабул итеп, намазга баса.

**МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА,**
**мәдрәсә шәкерте.**

Игътибар: бәйге!

## Каләмнәрегезне чарлагыз

“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр ноябрь ае буе кабул ителәләр. Аларны мәдрәсәнең электрон почтасына яки хат рәвешендә җибәрергә мөмкин.
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 8/28. Электрон адрес: mamadysh-medrese@mail.ru.**

## “Иң яхшы шәкерт”

1 нче октябрьдән Мамадыш мәдрәсәсе “Иң яхшы шәкерт” бәйгесе игълан итә. Әлеге бәйгенең максаты: дини гыйлем бирүне көчәйтү, популярлаштыру, студентларның белем сыйфатын яхшырту, укытучыларның белгечлек дәрәҗәсен арттыру, студентларны төрле иҗтимагый чараларда катнашуга кызыктыру. Бәйгенең нәтиҗәләре һәр ай азагында билгеләнеп торачак. Җиңүчеләрне бүләкләр көтә.

Белдерүләр

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.
*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (сатуда: Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)
*Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү.
*Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.
*Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте. Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

Укырга чакырабыз

## Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 уку елына шәкертләр туплый.
Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.
Көндезге бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты – өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей базасында алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.
Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:
**1) Гариза. 2) Белем турында таныклык. 3) 086-формасында сәламәтлек турында белешмә. 4) Паспорт (копия). 5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт. 6) №26 формасында шәхси медицина картасы**
**Документлар кабул ителә.**
*Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үстерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.*
*Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы 8/28,*
**Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**